| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

«28» ноября 2024ел № 151

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 21 октябрендәге 444 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләгән тренерларны ярышларда алган нәтиҗәләре өчен шулай ук спортчы-инструкторларны һәм спортчыларны бүләкләү Тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Район Башкарма комитетының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенең 2024 елның 20 ноябрендәге 181 номерлы хатын карап, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 07 мартындагы 127 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 31 октябрендәге 979 номерлы «Хезмәткәрләргә-спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларының яшь белгечләренә акчалата түләүләр билгеләү турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» карары нигезендә, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге карамагындагы муниципаль физкультура спорт учреждениеләрендә эшләүче яшь белгечләргә хуҗалык эшләрен җайга салу өчен бер мәртәбә акчалата түләү бирүне төгәлләштерү максатларында, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 21 октябрендәге 444 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче тренерларга, тренер-инструкторларга һәм спортчыларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен акчалата түләү тәртибенең 11 пунктына, түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«11. Хуҗалыкны төзекләндерү өчен хезмәткәргә (яшь белгечкә) бер мәртәбә 100000,00 (йөз мең) сум күләмендә акчалата түләү башкарыла.».

2. Әлеге карарның 1 пунктының гамәлдә булуы 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин